ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлегенең Тубылгы Тау авылында
2022 елда үзара салым кертү турында

№ 2

2021 елның 22 ноябре

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлегенең Тубылгы Тау авылында гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлегенең Тубылгы Тау торак пункты территориясендә теркәлгән балигъ булган һәрбер гражданнан, көндезге бүлектә укучы студентлар, сугыш ветераннарының тол хатыннары, сугыш ветераннары һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, I группа инвалид, 75 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзсалым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, Тубылгы Тау Бистәсенә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү), Мира, Яшьләр урамы, Дуслык урамы буенча;
- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эш өчен түләү);
- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- юлларны грейдлау (килешү буенча эшләр өчен түләү).

3. Тубылгы Тау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән әлеге карарны игълан итәргә, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында (http://novosheshminsk. tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Халык җыенында рәислек итүче
Тубылгы Тау авыл җирлеге башлыгы
Яңа Чишмә муниципаль районы

Ф.Ф. Исмагилов

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА" ... СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ ... ТАТАРСТАН
Р 06-597/14
СОВЕТ
ТУБЫЛГЫТАУСКОГО
СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ